# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

"Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында" 1993 елның 15 июлендәге 1936-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1993, N 6-7) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. Тулай торакларда, махсуслаштырылган йортларда һәм ябык хәрби шәһәрчекләрдәге йортларда, шулай ук авария һәм хәрабә хәлендәге йортларда торак урыннары хосусыйлаштырылмый.

Хәрабә хәлендәге йортта яшәүче барлык гражданнар риза булган очракта, йорт хәрабә хәлендәге торак фонды составыннан төшереп калдырыла. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру гомуми нигезләрдә башкарыла.

Халык депутатларының җирле Советлары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән берлектә, һөнәр берлекләренең (аларның тиешле органнары аша), ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләт бирелгән вәкилләренең фикерен исәпкә алып, хезмәт торак урыннарының хосусыйлаштырылмый торган өлешен билгелиләр".

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 28 марты
N 485